**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 2 сентябрь № 610

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 17 май, 321 нче; 2016 ел, 9 июль, 465 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү

фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати ярдәм күрсәтү һәм үз бизнесыңны төзүне популярлаштыру буенча кампания оештыру;

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасын төзү һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү чаралары нәтиҗәлелеген мониторинглау.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков